ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.12.2020 г. Заинск № 596

**«Адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 12 декабрендәге 2844 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Авыр тормыш хәлендә калган затларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру, матди ярдәм күрсәтү турында гражданнарның гаризаларын карау эшен оештыруны камилләштерү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 12 декабрендәге 2844 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 17.11.2015 ел, №1907; 17.10.2016 ел, №2279; 24.11.2016 ел, №2687; 01.02.2018 ел, №157; 02.04.2018 ел, №509; 10.05.2018 ел, №739; 22.06.2018 ел, №1023; 14.02.2019 ел, №51; 20.03.2019 ел, №141; 17.06.2019 ел, №313; 09.08.2019 ел, №423; 16.03.2020 ел, №100; 21.10.2020 ел, №466 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) гражданнарга адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча нигезләмәнең 3.1. пункты 5 абзацына үзгәреш кертергә: «- елына 100 000 сумга кадәр» сүзләрен «- елына 200 000 сумга кадәр» сүзләре белән алмаштырырга.
2. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

И.В.Шакирзянова
7 07 66
Юрист
7 10 27